**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АКСАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# К А Р А Р

**№ 138** **28 ноябрь 2024 ел**

**“Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында” 2018 елның 25 апрелендәге 107 номерлы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, Зәй муниципаль районының Югары Аксар авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2018 елның 25 апрелендәге 107 номерлы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге Советының “Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә хакында” карарына (25.05.2018 № 109, 22.09.2020 № 6, 30.12.2021 № 18, 01.10.2022 № 72, 22.11.2022 № 75, 01.03.2023 № 91, 24.06.2024 № 129 Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге Советының үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәгә:

2.2 пунктта «13 323 сум» сүзен «13 990 сум” сүзе белән алыштырырга;

2.14 пунктта «13 323 сум» сүзен «13 990 сум” сүзе белән алыштырырга;

1.2. Әлеге карар белән расланган “Зәй муниципаль районы Аксар авыл жирлеге үзидарәсенең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә, белгечләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында” нигезләмәгә 2 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“ Аксар авыл җирлеге башлыгына акчалата түләү күләме

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 20 991 |

2. Карарны Аксар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре җирле үзидарә органнары житәкчеләренә штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет Рәисе** **Ю.И.Гыйлманов**